| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 5 сентябрь № 639

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 16 сентябрь, 737 нче; 2011 ел, 4 октябрь, 829 нчы; 2012 ел, 1 июнь, 463 нче; 2014 ел, 2 апрель, 213 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пункттагы «бүлегенә» сүзен «идарәсенә» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 16 сентябрь, 737 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 4 октябрь, 829 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 1 июнь, 463 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 2 апрель, 213 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\639.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 25 июнь, 451 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 639 нчы карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы (алга таба – Совет) – Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен (алга таба – телләр өлкәсендә дәүләт сәясәте) камилләштерү, Татарстан Республикасы гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне куллануга хокукларын тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар, шул исәптән эшчәнлекләрен әлеге өлкәдә гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар арасындагы хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында төзелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы даими гамәлдә булган орган.

2. Совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

3.1. Телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүнең, гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне куллануга хокукларын тәэмин итүнең өстенлекле юнәлешләрен һәм механизмнарын, шулай ук әлеге өлкәдә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга һәм камилләштерүгә юнәлдерелгән чараларны кабул итү буенча өстенлекле юнәлешләрне һәм механизмнарны билгеләү.

3.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга, гражданнарның Татарстан

Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне куллануга хокукларын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар арасындагы хезмәттәшлекне тәэмин итү.

3.3. Телләр өлкәсендәге дәүләт сәясәтенә кагылышлы программалар һәм проектларны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү, әлеге программалар һәм проектлар нәтиҗәлелеген анализлау, кирәк булган очракта аларны үзгәртү турында тәкъдимнәр әзерләү.

3.4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, фәнни оешмаларга, белем бирү оешмаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре каршындагы телләр турында законнарны тормышка ашыру комиссияләренә үзенең компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча методик яктан ярдәм һәм консультация ярдәме күрсәтү.

4. Советның төп вазыйфалары түбәндәгеләр:

4.1. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 ел, 8 июль, 1560-XII нче Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын һәм телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенә кагылышлы башка норматив хокукый актларны тормышка ашыруны анализлау.

4.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагына Татарстан Республикасында телләрнең торышын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү.

4.3. Норматив хокукый актларны үзгәртү турында тәкъдимнәр эзерләү һәм үзенең компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына кертү.

4.4. Законнар проектларын һәм телләр сәясәте өлкәсендә башка норматив хокукый актларны әзерләүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы оешмаларының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

4.5. Үзенең эшчәнлек өлкәсе мәсьәләләре буенча законнар проектлары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә йомгаклар әзерләү.

5. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен, Совет түбәндәге хокукларга ия:

5.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, мәдәният һәм сәнгать оешмаларыннан, фәнни оешмалардан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалардан, шулай ук аларның вазыйфаи затларыннан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар соратып алу һәм кабул итү.

5.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларын, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләрен үзенең утырышларына чакыру һәм аларның хисапларын тыңлау.

5.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан үткәрелә торган, Совет компетенциясенә караган актуаль мәсьәләләргә багышланган киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үзенең вәкилләрен җибәрү.

6. Совет, аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнашучы Совет рәисе, аның өч урынбасары, секретаре һәм Совет әгъзалары составында төзелә. Совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

7. Татарстан Республикасы Премьер-министры Совет рәисе булып тора.

8. Совет, аңа йөкләнгән бурычлар нигезендә, үзенең әгъзалары арасыннан, шулай ук Совет составына кермәгән галимнәр, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, педагоглар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләре арасыннан даими һәм вакытлы комиссияләр (эшче төркемнәр) төзи ала.

9. Совет утырышларының көн тәртибен һәм аны оештыруны әзерләүне, шулай ук Совет эшчәнлегенең гамәлдәге мәсьәләләрен хәл итүне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Совет секретаре гамәлгә ашыра.

10. Совет утырышлары кимендә алты айга бер тапкыр үткәрелә. Совет уырышының көн тәртибе, көне һәм аны үткәрү тәртибе Совет рәисе тарафыннан билгеләнә. Кирәк булган очракта Советның чираттан тыш утырышлары үткәрелә ала.

11. Совет утырышын Совет рәисе яки аның кушуы буенча Совет рәисе урынбасарларының берсе үткәрә.

12. Совет утырышы, Совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше булган очракта, тулы хокуклы дип санала.

13. Совет карарлары утырышта катнашкан Совет әгъзаларының күпчелеге тавыш биргән очракта кабул ителә. Тавышлар тигез булса, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.

14. Совет карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, һәм анда Совет утырышында рәислек итүче тарафыннан кул куела.

15. Совет карарларының үтәлешен тикшерүдә тоту Совет секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 25 июнь, 451 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 639 нчы карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составы**

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Совет рәисе |
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Совет рәисе урынбасары |
| Вәлиев Разил Исмәгыйль улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, Совет секретаре |

Совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Александровская Ирина Алексеевна | «Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары, Казан шәһәре 93 нче гимназиясе директоры (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | Лаеш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Барышев Александр Георгиевич | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Владимиров Николай Михайлович | Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе урынбасары – Татарстан халыклары ассамблеясе Советы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Галиуллин Камил Рәхим улы | теоретик һәм гамәли лингвистика кафедрасы мөдире, Казан (Идел буе) федераль университетының филология факультеты деканы (килешү буенча) |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры (килешү буенча) |
| Гыйльметдинов Илдар Ирек улы | Татар федераль милли-мәдәни автономиясе советы рәисе, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры (килешү буенча) |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Жолобов Олег Феофанович | Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының рус теле һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |
| Закиров Ринат Зиннур улы | «Бөтендөнья татар конгрессы» халыкара иҗтимагый берләшмәләр берлеге Башкарма комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Җамалетдинов Рәдиф Рифкать улы | Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зарипов Айрат<br>Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Калинкин Денис<br>Геннадьевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кибец Валентина<br>Васильевна | Зеленодольск шәһәренең А.С.Пушкин исемендәге 9 лицей директоры (килешү буенча) |
| Кисапова Оксана<br>Алексеевна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Корбанов Рафис<br>Харис улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Лаврентьев Александр<br>Петрович | «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм эшкуарлары ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе президенты, «Казан вертолет заводы» ачык акционерлык җәмгыятенең директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Леонов Владимир<br>Александрович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры |
| Мәһдиев Наил<br>Гамбәр улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Миңнуллин Ким<br>Мөгаллим улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры (килешү буенча) |
| Новиков Сергей<br>Владимирович | «Татарстан Республикасы Мордва милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Рәхмәтуллин Рауил<br>Шәйдәүләт улы | Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Романов Валентин<br>Серапионович | «Татарстан Республикасы Удмуртлар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сәгъдәтшин Илдар Камил улы | Татар китап нәшрияте директоры (килешү буенча) |
| Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Скоблионок Михаил Абрамович | «Татарстан Республикасы Яһүдиләр милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Третьяков Олег Александрович | «Татарстан Республикасы Марилар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фомин Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хәсәнов Гали Әхтәр улы | «Татарстан Республикасы Башкортлар корылтае» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хухунашвили Маринэ Мануиловна | Казан шәһәре «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге директоры (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Яковлев Константин Геннадьевич | Татарстан Республикасы Чуваш милли-мәдәни автономиясе рәисе (килешү буенча). |

______________________________